| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Иж-Бобьинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Иж-Бубый авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.10.2019 Иж-Бубый авылы № 3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иж-Бубый авыл җирлеге Иж-Бәйки авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иж-Бубый авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иж-Бубый авыл җирлеге башлыгы к а р а р б и р д е:

1. Иж-Бәйки авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2019 елның 07 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауные расларга: «I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, һәм ироктән мәхрүм итү урыннарында булган затлардан тыш, Иж-Бубый авыл җирлеге Иж-Бәйки авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2020 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1. Иж-Бәйки авылында су челтәрләренә хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, тирән насосларны ремонтлау

2.Иж-Бәйки авылындагы Колхоз урамы буенча юлга вак таш җәю һәм ремонтлау

3.Иж-Бәйки авылы урамнарын кардан чистарту

4.Иж-Бәйки авыл клубы тамбурын ремонтлау.

«ӘЙЕ» «ЮК".

3. Иж-Бубый авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Иж-Бобьинского сельского поселения
Иж-Бубый авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002460

Р.Р. ВАҺАПОВ